ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль районда бер муниципаль район муниципаль комиссиясе, шәһәр округында бер шәһәр округы муниципаль комиссиясе төзелә.

Шәһәр округы вәкиллекле органы карары буенча, шәһәр округы муниципаль комиссиясеннән тыш, өстәмә рәвештә шәһәр округы территориясе өлешендә эшләүче муниципаль комиссияләр (алга таба – шәһәр эче муниципаль комиссияләре) төзелергә мөмкин, ләкин шәһәр эче муниципаль комиссиясе Казан шәһәре шәһәр округында дүрттән артык һәм Чаллы шәһәре шәһәр округында өчтән артык төзелә алмый.

Компетенцияләрне шәһәр округы муниципаль комиссиясе һәм шәһәр эче муниципаль комиссияләре арасында бүлү тиешле шәһәр округы вәкиллекле органының хокукый акты белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «, 25 кешедән артык» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «урынбасары» сүзеннән соң «(урынбасарлары)» сүзен өстәргә;

3) 7 статьяда:

а) 1 өлештә «, 15 кешедән артык» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «урынбасары» сүзеннән соң «(урынбасарлары)» сүзен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Рәис җирле администрация башлыгы урынбасарлары арасыннан (шәһәр эче муниципаль комиссиясендә – шәһәр округы җирле администрациясе территориаль органы җитәкчесе урынбасарлары арасыннан) билгеләп куела.

Рәис муниципаль комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен шәхси җаваплы була, хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, муниципаль комиссия утырышын алып бара; муниципаль комиссия кабул итә торган документларга имза сала. Рәис булмаган очракта, аның функцияләрен рәис урынбасары (рәис урынбасарларының рәис тарафыннан билгеләнгән берсе) башкара.»;

4) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле $19^1$ пункт өстәргә:

«$19^1$) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы территориясендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эше турында хисапларны, шулай ук Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның сукбайлыгын, күзәтүчесезлеген, наркоманиясен, токсикоманиясен, алкоголизмын, хокук бозуларын, һәлак булуларын һәм имгәнүләрен кисәтү чаралары, хезмәт, торак һәм башка хокуклары бозылу турында башка мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм җибәрә, әлеге өлкәдә вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә;»;

5) 17 статьяда:

а) 7 өлештә «дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга» сүзләрен «тиешле дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга, «оешмаларга» сүзеннән соң «, гражданнарга» сүзен өстәргә;

б) 9 өлештә «күрсәтмәләрен» сүзеннән соң «тиешле» сүзен өстәргә, «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 13-ТРЗ